СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

02.06.2020 г.Зеленодольск № 289

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында Зеленодольск шәһәре Советының 2016 елның 9 сентябрендәге 89 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль милек реестрларын алып бару тәртибен раслау турында» 2011 елның 30 августындагы 424 номерлы боерыгы нигезендә, Зеленодольск шәһәре Советы **карар чыгарды**:

1. 2016 елның 9 сентябрендәге 89 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең тугызынчы абзацында «Татарстан Республикасы,» сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле сүзләр һәм саннар өстәргә:

Зеленодольск шәһәре Советының 2018 елның 29 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган карар,»;

1.2. Нигезләмәнең унынчы абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«- "Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында" 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законы белән»;

1.3. Нигезләмәнең 1.3 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«(2) Зеленодольск шәһәренең җирле үзидарә органнарына һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба - ЗМР Башкарма комитеты) тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт, федераль законнарда һәм Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән очракларда, шулай ук Зеленодольск шәһәре җирле үзидарә органнарының һәм ЗМР Башкарма комитетының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешендә каралган тәртиптә аларга тапшырылган мөлкәт (алга таба - 131-ФЗ номерлы Федераль закон);

1.4. Нигезләмәнең 1.3 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 һәм 4 өлешләре, 16 статьясындагы 3 өлеше һәм 16.2 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләре нигезендә Зеленодольск шәһәренең һәм ЗМР Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 һәм 1.1 өлешләре нигезендә Зеленодольск шәһәренең һәм ЗМР Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт.»;

1.5. 1. Нигезләмәнең 4 пунктын төшереп калдырырга;

1.6. Нигезләмәнең 1.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Зеленодольск шәһәренең муниципаль казнасын хуҗалык алып бару, оператив идарә итү хокукында муниципаль унитар предприятиеләргә һәм учреждениеләргә беркетелмәгән Зеленодольск шәһәре бюджеты акчалары һәм башка муниципаль мөлкәт төзи.»;

1.7. Нигезләмәнең 2.4 пунктындагы түбәндәге эчтәлекле бишенче абзацын төшереп калдырырга:

«-Зеленодольск шәһәре милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау;»;

1.8. Нигезләмәнең 2.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. ЗМР Башкарма комитетының муниципаль милеккә идарә өлкәсендәге вәкаләтләренә Зеленодольск шәһәре территориясендә түбәндәгеләр керә:

- Зеленодольск шәһәренең муниципаль милкендәге мөлкәт белән идарә итү, Зеленодольск шәһәренең муниципаль милек объектларын төзү, сатып алу, алардан файдалану, кушу һәм арендалау мәсьәләләрен хәл итү;

- Зеленодольск шәһәре Советы карары белән билгеләнә торган очракларда Зеленодольск шәһәре Советының килештерүенә (раславына) Зеленодольск шәһәре муниципаль мөлкәтен читләштерү турында тәкъдимнәр кертә, шул исәптән аны хосусыйлаштыру турында да;

- муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр булдыра, аларның эшчәнлек максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели, аларның уставларын раслый, муниципаль казна учреждениеләрен финанслауны

тәэмин итә, муниципаль учреждениеләрне һәм предприятиеләрне үзгәртеп кору һәм бетерү мәсьәләләрен хәл итә, аларның җитәкчеләрен контракт нигезендә билгели һәм вазыйфаларыннан азат итә;

- муниципаль милектәге предприятиеләр, оешмалар белән Зеленодольск шәһәренең икътисадый һәм социаль үсешендә хезмәттәшлек турында шартнамәләр төзи; Зеленодольск шәһәре территориясендә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә төрле милек рәвешләрендәге предприятиеләр төзүгә ярдәм итә;

- 2017 елның 1 гыйнварына кадәр полициянең участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазыйфа буенча вазыйфаларны хезмәткәр башкарган чорда торак урын бирә;

- Зеленодольск шәһәренең административ участогында эшләү өчен бина полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә бирә.».

1.9. Нигезләмәнең 3.3 пунктның 3 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3) арендалау хокуклары - арендаторлар; ышанычлы идарә итү - ЗМР Башкарма комитеты;»;

1.10. Нигезләмәне 3.3 пунктның 5 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

5) муниципаль милекне читләштергәндә милек хокукы-ЗМР Башкарма комитеты.»;

1.11. Нигезләмәнең 4.4 пункты үз көчен югалткан дип тану;

1.12. Нигезләмәнең 5.12, 5.13 пунктларында «Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестры» сүзләрен «Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестры»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәгеТатарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга .

**Зеленодольск шәһәре мэры урынбасары** **К. С. Антипов**